СОВЕТ УСАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4 с.Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Усали авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**
**№ 1-8** **от 17.05.2021ел.**

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2020 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №468-ФЗ Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы» нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендәге №3-37 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (05.06.2018 ел, № 6-32, 29.04. 2019 ел. №3-41,19.02.2020ел №5-50 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 23 статьяда:
- 4 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга»;
- 5 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2 29 статьяның 5 пункытында:
- 4 абзацта «капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;
- 5 абзацта «капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3 35 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3. Җир кишәрлекләренең чик күләме:
«Шәхси торак төзелеше», «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «Блоклы торак төзелеше» кебек җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1000 кв. м.
«Шәхси торак төзелеше», «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «Блоклы торак төзелеше» кебек җир кишәрлекләренең максималь күләме – 5000 кв. м.».
2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.И.Зиатдинов